Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы
Кунгәр авыл җирлеге Советы Карары

«14» мая 2021 ел № 25

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Кунгәр авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күнгәр авыл җирлегендә халык тыңлауларын (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2018елның 15 декаберендәге 84 номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында»

«Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына территорияләрне комплексллы үстерүне тәэмин итү максатларында үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 30 декабрендәге 494-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә,Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Кунгәр авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Кунгәр авыл җирлеге Советының 2018 елның 15 декабрендәге 84 номерлы карары нигезендә расланган «Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күнгәр авыл җирлегендә халык тыңлауларын (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» гы карарына 1 нче номерлы кушымта нигезендә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә.

2. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында, Әтнә муниципаль районының Интернет челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru веб–адресы буенча һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында: pravo.tatarstan.ru веб–адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми халыкка игълан ителгәннән соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җавапчылыгымда калдырам.

Әтнә муниципаль районы
Кунгәр авыл җирлеге башлыгы: И.И.Салахов

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы
Кунгәр авыл җирлеге Советының
2021елның «14» маенда № 25 номерлы карарына
1 нче номерлы кушымта

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Кунгәр авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күнгәр авыл җирлегендә халык тыңлауларын (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2018 елның 15 декаберендәге 84 номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында»

Кунгәр авыл җирлеге Советының 2018 елның 15 декабрендәге 84 нче номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**12 статьяның 3 абзацын түбәндәге эчтәлекле сүзләр белән тулыландырырга:**

«Җирлекнең генераль планына, шәһәр округының Генераль планына үзгәрешләр әзерләү очракларыннан тыш, территорияне комплексы үстерү турында Карар кабул ителү белән бәйле җәмәгать тыңлаулары яисә гавами тыңлаулар, аңа карата территорияне комплекслы үстерү турында Карар кабул ителгән территория чикләрендә үткәрелергә мөмкин».